| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района** | | **Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» 03 2021 № 93

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының «Суд тарафыннан хокукый сәләтсез
яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган
гражданнарга һәм балигъ булмаган гражданнарга карата опека
һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең
административ регламентларын раслау турында»
2018 елның 25 декабрендәге 732 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2020 ел, 26 ноябрь, 7036 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 ел, 2 ноябрь, под-1148/20 номерлы, 2020 ел, 5 ноябрь, под-1158/20 номерлы, 2020 ел, 11 декабрь, под-1326/20 номерлы, 2020 ел, 9 декабрь, под-1305/20 номерлы күрсәтмә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алу турында» 26.11.2020 ел, 26 ноябрь, 04/13-06/5857 номерлы хаты, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Норматив хокукый актны дәүләт теркәве турында» 2020 ел, 22 гыйнвар, 645/21 номерлы хаты нигезендә, Аксубай муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 1.1,1.3,1.4, 1.6 пунктчалары ( 1, 3, 4, 6 нче кушымталар) Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Суд тарафыннан хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган гражданнарга һәм балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2018 елның 25 декабрендәге 732 номерлы карарның (26.02.2021 ел, № 67 карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыкларын:
- «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга опекун (попечитель) итеп билгеләү (түләүле яисә түләүсез шартларда) яисә опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 02.11.2020 № под-1148/20;
- «Банкта яки башка кредит оешмасында счет (кертем) булган балигъ булмаган балаларга исәп-хисап счеты ябуга, исәптән төшерү, күчерү, тоту буенча алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 05.11.2020 № под -1158/20;
- «Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын уллыкка алу мөмкинлеге һәм уллыкка алучыларга кандидат буларак исәпкә кую турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 11.12.2020 № под-1326/20;
- "Балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен тартып алу буенча алыш-бирешләрне башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 09.12.2020 № под-1305/20-
Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю,Зайцев